КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 декабрь г.Казань № 1257

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен билгеләү турында» 2011 ел, 27 декабрь, 1079 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен билгеләү турында» 2011 ел, 27 декабрь, 1079 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 июль, 553 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларына техник тикшерү үткәрү турында» 2011 елның 5 декабрендәге 1008 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларына техник тикшерү үткәрү кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1434 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 27 декабрь, 1079 нчы
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 21 декабрь, 1257 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында транспорт чараларына
техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре

| Т/с | Транспорт чаралары категориясе (яки махсус транспорт чарасы әзерләнгән транспорт чарасы категориясе)[1] | Транспорт чарасы төре | Транспорт чарасына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | M1 | Пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган һәм автомобильләр йөртүче урыныннан тыш утыру өчен иң күбе сигез урыны булган транспорт чаралары (җиңел автомобильләр) | 510 |
| 2. | M2 | Пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган, автомобильләр йөртүче урыныннан тыш утыру өчен иң күбе сигездән артык урыны булган, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 5 тоннадан артмаган транспорт чаралары | 1 003 |
| 3. | M3 | Пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган, автомобильләр йөртүче урыныннан тыш утыру өчен иң күбе сигездән артык урыны булган, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 5 тоннадан арткан транспорт чаралары | 1 224 |
| 4. | N1 | Йөкләр ташу өчен билгеләнгән, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы иң күбе 3,5 тонна булган транспорт чаралары | 544 |
| 5. | N2 | Йөкләр ташу өчен билгеләнгән, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 3,5 тоннадан арткан, ләкин 12 тоннадан кимрәк булган транспорт чаралары | 1 071 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 6. | N3 | Йөкләр ташу өчен билгеләнгән, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 12 тоннадан арткан транспорт чаралары | 1 156 |
| 7. | O1,O2 | Техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы иң күбе 3,5 тонна булган тагылмалар | 425 |
| 8. | O3,O4 | Техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 3,5 тоннадан арткан тагылмалар | 748 |
| 9. | L | Мототранспорт чаралары | 200 |
| 10. | M1 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары | 544 |
| 11. | M2 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары | 1 003 |
| 12. | M3 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары | 1 156 |
| 13. | N1 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары, транспорт чаралары – цистерналар, транспорт чаралары – сыекландырылган углеводород газларын ташу һәм салу өчен цистерналар, транспорт чаралары – фургоннар, транспорт чаралары – кешеләрне йөртү урыннары булган фургоннар, автоэвакуаторлар | 578 |
| 14. | N2 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары, автоэвакуаторлар, йөк күтәрү җайланмалары булган транспорт чаралары, транспорт чаралары – цистерналар, транспорт чаралары – сыекландырылган углеводород газларын ташу һәм салу өчен цистерналар, транспорт чаралары – фургоннар, азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары | 1 122 |
| 15. | N3 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары, автоэвакуаторлар, йөк күтәрү җайланмалары булган транспорт чаралары, транспорт чаралары – цистерналар, транспорт чаралары – сыекландырылган углеводород газларын ташу һәм салу өчен цистерналар, транспорт чаралары – фургоннар, азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары | 1 207 |
| 16. | O1,O2 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары, транспорт чаралары – цистерналар, транспорт чаралары – сыекландырылган углеводород газларын ташу һәм салу өчен цистерналар, транспорт чаралары – фургоннар, азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары | 442 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 17. | O3,O4 | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары, автоэвакуаторлар, йөк күтәрү җайланмалары булган транспорт чаралары, транспорт чаралары – цистерналар, транспорт чаралары – сыеклandырылган углеводород газларын ташу һәм салу өчен цистерналар, транспорт чаралары – фургоннар, азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары | 782 |
| 18. | L | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары | 187 |
| 19. | N1 | Махсус транспорт чаралары, транспорт чаралары – нефть продуктларын ташу һәм салу өчен цистерналар | 629 |
| 20. | N2 | Махсус транспорт чаралары, транспорт чаралары – нефть продуктларын ташу һәм салу өчен цистерналар, транспорт чаралары – кешеләрне йөртү урыннары булган фургоннар | 1 224 |
| 21. | N3 | Махсус транспорт чаралары, транспорт чаралары – нефть продуктларын ташу һәм салу өчен цистерналар, транспорт чаралары – кешеләрне йөртү урыннары булган фургоннар | 1 326 |
| 22. | O1,O2 | Махсус транспорт чаралары | 493 |
| 23. | O3,O4 | Махсус транспорт чаралары | 867 |
| 24. | N1 | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары | 595 |
| 25. | N2 | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары, йөк ташу өчен тагылма (прицеп-роспуск) кулланыла торган транспорт чаралары | 1 173 |
| 26. | N3 | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары, йөк ташу өчен тагылма (прицеп-роспуск) кулланыла торган транспорт чаралары | 1 275 |
| 27. | O1,O2 | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары, транспорт чаралары – нефть продуктларын ташу һәм салу өчен цистерналар | 476 |
| 28. | O3,O4 | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары, транспорт чаралары – нефть продуктларын ташу һәм салу өчен цистерналар | 816 |
| 29. | N1 | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары | 714 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 30. | N2 | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары | 1 394 |
| 31. | N3 | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары | 1 496 |
| 32. | O1,O2 | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары | 510 |
| 33. | O3,O4 | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары | 901 |

[1]Транспорт чарасын тиешле категориягә кертү Таможня берлеге комиссиясенең «Таможня берлегенең «Көпчәкле транспорт чаралары иминлеге турында»гы техник регламентын кабул итү хакында» 2011 ел, 9 декабрь, 877 нче карары белән кабул ителгән Таможня берлегенең «Көпчәкле транспорт чаралары иминлеге турында»гы техник регламентына теркәлгән 1 нче кушымтада билгеләнгән классификация буенча башкарыла.